УДК 930.2:821.512.145-93
EDN YRWGBA
DOI 10.24412/2073-7475-2026-4-192-199

Йосыф Гәрәй архивында балалар әдәбияты: милли тәрбия һәм традицион кыйммәтләр

Л. И. Минһаҗева,

Казан федераль университеты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе

Children's literature in Yusuf Garey's archive: national upbringing and traditional values

L. I. Mingazova,

Kazan Federal University, Kazan, the Republic of Tatarstan, Russian Federation

Аннотация

Статья посвящена исследованию архива татарского и башкирского писателя, педагога и публициста Юсуфа Гарея (1904-1988) как комплекса источников по истории национальной культуры, детской литературы и семейного воспитания. Основу работы составили материалы фонда № 136 Центра письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан: рукописи и машинописные тексты, протоколы литературных обсуждений, письма, воспоминания, педагогическая публицистика и документы о реабилитации. Цель исследования – выявить связь между общественно-политической биографией Ю. Гарея и эволюцией его представлений о детстве, родном языке и культурной преемственности. Источниковедческий анализ письма Н. С. Хрущеву (1956 г.), справки Верховного Суда РСФСР (1957 г.), материалов о детской литературе и статей 1960-1980-х гг. показывает, что репрессия 1940 г. прервала сформировавшуюся в 1930-е гг. педагогическую и литературно-организационную деятельность автора, но не разрушила ее ценностного ядра.

Abstract

This article examines the archive of the Tatar and Bashkir writer, educator, and publicist Yusuf Garey (1904-1988) as a body of sources on the history of national culture, children's literature, and family upbringing. The study is based on materials from Fond No. 136 at the Centre for Written and Musical Heritage of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, Tatarstan Academy of Sciences, including manuscripts, typescripts, minutes of literary discussions, correspondence, memoirs, pedagogical essays, and rehabilitation papers. The article aims to establish the relationship between Garey's political biography and the evolution of his ideas about childhood, the native language, and cultural continuity. An analysis of his 1956 letter to Nikita Khrushchev, the 1957

certificate by the Supreme Court of the RSFSR, documents on children's literature, and essays from the 1960s–1980s demonstrates that the repression of 1940 interrupted the pedagogical and literary-organisational work he had developed during the 1930s, but did not destroy its core values.

Ключевые слова
Юсуф Гарей, архив писателя, политические репрессии, реабилитация, детская литература, история детства, национальное воспитание.

Keywords
Yusuf Garey, writer's archive, political repression, rehabilitation, children's literature, history of childhood, national upbringing.

Рәхмәт сүзе
Мәкалә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.

Acknowledgements
This work was supported by the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan within the framework of the State Program of the Republic of Tatarstan "Preservation, Study, and Development of the State Languages of the Republic of Tatarstan and Other Languages of the Republic of Tatarstan".

Совет чоры балалар әдәбияты һәм китаплары – төрле аспектларда өйрәнелгән өлкә[1]. Галимнәр фикеренчә, бу чорны өйрәнгәндә төп ике юнәлеш аеруча мөһим. «Беренче юнәлеш – дәүләтнең "яңа кеше", коллектив мөнәсәбәтләр һәм коммунистик тәрбия турындагы карашлары; икенчесе – гаилә мөнәсәбәтләре, халык уеннары, бишек җыры һәм көнкүреш хезмәте аша дәвам иткән мәдәни тәҗрибә»[2]. Алар бер-берсен тулысынча кире какмый, ләкин һәрвакыт тәңгәл дә килми. Шәхси архивлар әлеге катламнарның рәсми документларда, публицистикада, балалар әсәрләрендә һәм хатларда чагылуын өйрәнергә мөмкинлек бирә. Шундый чыганаклардан, язучы, педагог һәм публицист Йосыф Ибраһим улы Гәрәйнең (1904-1988) фонды кызыклы: анда балалар әсәрләре, китап чыгару турында публицистика, редакцион фикер алышу, гаилә тәрбиясе һәм туган телгә караган материаллар бер архив контекстында очраша.

Әдипнең шәхси архивын хатыны Газизә Шакировна Лотфуллина 1991 елда Г. Ибраһимов исемендәге институтның кулъязмалар бүлегенә тапшыра. Хәзер ул ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә (алга таба – Мирасханә) 136нчы фондта саклана. Беренче тасвирламага 70 саклау берәмлеге кертелгән: иҗади кулъязмалар, публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләр, көндәлекләр, хатлар, фотосурәтләр һәм реабилитация документлары[3].

Йосыф Гәрәй укытучы, мәгариф хезмәткәре, дәреслекләр төзүче, язучы, тәрҗемәче буларак 1920-1930 елларда Башкортстанның күптелле мәдәни мохитендә эшли. 1940 елгы репрессия аның иҗади һәм һөнәри биографиясен өзә. 1957 елгы реабилитациядән һәм 1958 елда Уфага кайтканнан соң ул балалар әдәбияты, гаилә тәрбиясе, туган тел һәм мәдәни хәтер мәсьәләләренә яңадан мөрәҗәгать итә[4]. Шуңа күрә Й. Гәрәй архивы бер авторның педагогик карашларын

гына түгел, XX гасыр шартларында милли мәдәни дәвамчанлыкның саклануын да күзәтергә мөмкинлек бирә.

Мәкаләнең чыганак корпусына дүрт төр документ алынды. Беренчесе – 1930 еллардагы әдәби-оештыру эшчәнлеген һәм балалар әдәбиятына, балалар китабына таләпләрне чагылдырган киңәшмә, секция материаллары. Икенчесе – 1940 елгы хөкемгә, 1956 елда Н. С. Хрущевка язылган гаризага һәм 1957 елгы реабилитациягә бәйле документлар. Өченчесе – балалар өчен әдәби әсәрләр һәм педагогик-публицистик текстлар. Дүртенчесе – хатлар, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов турында җыелган истәлекләр, туган тел турындагы язмалар. Төрле жанрдагы чыганакларны бергә карау авторның аерым фикерләрен генә түгел, аларның барлыкка килү һәм үзгәрү тарихын күзәтергә ярдәм итә.

Тикшерүнең максаты – Й. Гәрәйнең сәяси һәм иҗади биографиясе контекстында балалар әдәбияты һәм милли тәрбия турындагы карашларының формалашуын тарихи яктан бәяләү.

Йосыф Гәрәйнең балалар әдәбиятына карашы мәгариф системасындагы эш тәҗрибәсеннән формалаша. Биографик материалларга караганда, ул Бәләбәй педагогия курсларында укый, укытучы һәм мәгариф инспекторы булып эшли, Башкортстан Мәгариф халык комиссариатында хезмәт куя, башкорт мәктәпләре өчен әлифба, дәреслекләр һәм программалар әзерләүдә катнаша. 1936-1937 уку елында Башкорт дәүләт педагогия институтында рус теле һәм әдәбиятын укыта[5].

1936 елгы «балалар әдәбияты киңәшмәсе» материалы һәм 1940 елның 28 гыйнварында узган комиссия утырышы беркетмәсе балалар әдәбияты республика мәдәни сәясәтендә махсус өлкә буларак каралуын дәлилли[6]. Мондый документлар авторлар, нәшрият һәм әдәби оешмалар арасында вазифалар бүленешен, кулъязмаларга куелган идея-сәнгать таләпләрен, тәрҗемә һәм оригиналь әсәрләр нисбәтен өйрәнү өчен әһәмиятле булуы белән бергә, Й. Гәрәйнең балалар әдәбияты белән бәйләнешенең чишмә башын да ачыклый.

Башкортстан Язучылар берлеге каршындагы балалар әдәбияты секциясенең 1959 елның 22 маендагы утырышы беркетмәсе дә шушы дәвамчанлыкны күрсәтә. Анда Й. Гәрәйнең әкиятләре, җырлары һәм шигырьләре идея юнәлеше, композиция, тел һәм шигырь техникасы ягыннан тикшерелә. Бер өлешен нәшриятка тәкъдим итү, кайберләрен кыскарту һәм эшкәртү кирәклеге әйтелә[7].

1960 елда язылган «Алтыда күргән алтмышка барсын» мәкаләсендә автор үзе дә бу өлкәдәге төп критерийларны ача. Күчермәнең хәзерге укылышы буенча, бер елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен башкорт телендә ике оригиналь китап, икенче елда ике оригиналь һәм бер тәрҗемә китап чыккан. 1960 елда биш оригиналь һәм ике тәрҗемә китап нәшер ителгән, 1961 ел планы дүрт оригиналь һәм өч тәрҗемә әсәрне күздә тоткан. Автор моны Татарстандагы басма күләме белән чагыштыра һәм аерманы язучылар җитмәү белән түгел, эшнең Мәгариф министрлыгы, нәшрият һәм иҗат оешмалары тарафыннан планлаштырылмавы белән аңлата[8]. Бу мәкаләне, мондый статистика китерүне совет чоры балалар әдәбиятына авторның шәхси мөнәсәбәте буларак бәяләргә мөмкин. Й. Гәрәйнең максаты – республикада нәниләр өчен китап җитештерүнең түбән дәрәҗәсен күрсәтү. Ул балалар бакчаларына китаплар барып җитмәвен, урыннарда текстларның ашыгып тәрҗемә ителүен, рәссамнарның хайван, үсемлек сурәтләрен төшерүдә хаталар җибәрүен тәнкыйтьли. Шушы күзәтүләр балалар

китабының өч функциясен ача: ул телгә өйрәтә, белем бирә һәм эстетик зәвык формалаштыра. Тексттагы яки рәсемдәге төгәлсезлекләр шуңа күрә гади бизәлеш кимчелеге түгел, баланың танып белү тәҗрибәсен ялгыш юлга кертеп җибәрү булып чыга.

Й. Гәрәй фикерләвендә нәниләр китабының ике авторы бар: язучы һәм рәссам. Алар икесе дә бала алдындагы фәнни һәм әхлакый җаваплылыкны бүлешә. Шул ук вакытта ул «үгет-дидактика – әдәбият түгел» дип, тәрбияне коры нәсыйхәткә тиңләүгә каршы чыга. «Китап баланың фантазиясен, телен, көлү һәм гаҗәпләнү сәләтен үстерергә тиеш»[9]. Әлеге таләпләр 1930 еллардагы мәгариф хезмәткәре тәҗрибәсе белән 1960 еллардагы публицист позициясен уңышлы тоташтыра.

Й. Гәрәйнең иҗади биографиясен 1940 елгы репрессиядән аерып өйрәнү мөмкин түгел. 1956 елның 5 июнендә Н. С. Хрущевка язган күләмле хатында ул үзен Башкортстан Язучылар берлегенең элекке секретаре дип таныштыра, 1940 елның апрелендә кулга алынуын һәм 15 июльдә РСФСР Җинаять кодексының 58-10 маддәсе буенча ун елга ирегеннән, аннан соң биш елга хокукларыннан мәхрүм ителүен хәбәр итә[10]. Хат – юридик гариза гына түгел, репрессия кичергән язучының үз биографиясен һәм иҗади намусын акларга омтылышы да.

Автор хөкемнең нигезендә әдәби текстларны контексттан аерып уку һәм бәяләү торуын күрсәтә. «Байрак – Ил» шигырендәге «ут» сүзе – илһам түгел, «кайгы»; Ленинның байрактан «көлүе» – елмаю түгел, Сталиннан мыскыллап көлү дип аңлатылган. «Ленин» шигырендәге метафоралар һәм «Кунак» әсәрендәге әдәби бәяләр дә сәяси гаепләүгә әверелгән. Й. Гәрәй Габдулла Тукай, Максим Горький һәм башкорт шагыйрьләре мисалында «ут» һәм «көлү» сүзләренең поэтик мәгънәләрен аңлата. Шулай итеп, хатта филологик дәлил юридик яклау чарасы булып хезмәт итә: автор җинаять дип бәяләнгән фикернең текста булмавын контекст һәм поэтик семантика ярдәмендә исбатларга тырыша.

Шул ук вакытта Й. Гәрәй үзен Ленинга тугрылыклы совет язучысы итеп күрсәтә, XX съезд карарларына һәм шәхес культының фаш ителүенә таяна. «Мин тордым. Мин терелдем» мәгънәсендәге эмоциональ формулалар реабилитация өметен генә түгел, иҗатка кире кайтуны да белдерә. Ул кулъязмаларын кайтаруны, юк ителгән китапларын торгызуны һәм Язучылар берлегендәге әгъзалыгын яңартуны сорый: «На чем формально основан приговор? На стихотворении “Страна-Знамя” (журнал “Октябрь”, № 2, 1938, Уфа) оторвали из контекста четыре строчки, разложили анатомически и вывели противоположную мысль… Растолковали слово “огонь” в смысле “горе”. Во всем мире нет, видно, ни одного поэта, который не употребил бы слово “огонь” / гореть и т. д. в смысле вдохновение, сила, энергия. … Я ходатайствую о том, чтобы сняли с меня это позорное клеймо проклятия, вернули мои рукописи, восстановили изъятые книги и восстановили меня членом С[оюза] С[оветских] п[исателей]. Я даю клятву оправдать доверие. Я смогу дать народу сделать больше, чем делаю сейчас…

Обидно и тяжело безвинно так долго страдать!»[11].

1957 елның 22 октябрендәге РСФСР Югары Суды Президиумының карары белән 1940 елгы хөкем карары гамәлдән чыгарыла, җинаять составы булмау сәбәпле эш туктатыла. Бу хакта 1957 елның 18 декабрендәге № 1585-пс 7 санлы белешмәсендә тулысынча китерелгән[12]. Документ репрессия фактын һәм реабилитацияне раслый.

1958 елда Уфага кайтканнан соң Й. Гәрәй, гомум әдәбияттагы эшчәнлек белән бергә, балалар әдәбияты һәм тәрбия юнәлешендә дә публицистик мәкаләләр, әдәби әсәрләр язу эшенә керешә. Әмма, аларны инде «элекке эшнең дәвамы» дип кенә бәяләү дөрес булмас. Репрессия тәҗрибәсеннән соң аның текстларында хак сүз, өлкәнәрнең үз гамәле өчен җавап бирүе, әдәбиятны бозып аңлатуга каршы тору темаларының аеруча көчле яңгыравы күзәтелә.

1960-1980 еллардагы язмаларында Й. Гәрәй баланы өлкәннәр фикерен сүзсез кабул итүче объект итеп түгел, күзәтүче, сорау бирүче һәм үз хөкемен чыгара башлаган шәхес итеп сурәтли. Мисал өчен, «Бала бәхете – тәрбиядә» мәкаләсенең төп тезисы – тәрбиянең фән генә түгел, сәнгать тә булуы. Автор балага көч куллануны, җен, шүрәле, убыр һәм үтә дини карашлар белән куркытуны тәнкыйтьли. Әкият жанрын ул кире какмый, «аның фантазия һәм дөньяны танып белү өчен кирәклеген ассызыклый»[13]. Каршылык әкият белән дөньяви белем арасында түгел, ә образны бала иреген кысу өчен куллану белән аны иҗади үстерү арасында туа.

Мәкаләдә совет педагогикасының «гражданин», «коллектив», «җәмгыять файдасы» кебек төшенчәләре еш кулланыла. Алар чыганакның тарихи телен тәшкил итә. Әмма Й. Гәрәй коллективизмны абстракт лозунглар аша түгел, көндәлек тәртип аша аңлата, нәтиҗәдә, рәсми категорияләр этик талаплар югарылыгында тоныклана төшә.

Й. Гәрәй язмаларында, иҗатында тәрбиянең иң нәтиҗәле чарасы – өлкәннәрнең үз гамәле. Ул ата-ананың балага аерым «тәрбия сәгате» үткәрүеннән бигрәк, өйдә ничек сөйләшүе, хезмәтне бүлүе, исерткеч эчемлеккә, көч куллануга һәм ялганга мөнәсәбәт күрсәтүе әһәмиятле дип саный. «Чыңлатыйк әле, кызым!» миниатюрасында, мисал өчен, өлкәннәр өч яшьлек кызны бокал чәкештерү «йоласына» өйрәтә; «Сук әле, улымда» сабыйның ата-анасына сугуын көлеп хуплау бар. Соңрак шул гамәлләрнең көлкеле башлангычы өлкәннәр өчен әхлакый фаҗигагә әверелә[14]. «Коедагы бала», «Фаҗигадән көлке» кебек кыска хикәятләрендә исә автор баланың өлкәннәр сүзен туры мәгънәдә кабул итүдән туган фаҗигане тасвирлый. Ягъни, балага кечкенәдән дөрес мәгълүмат бирү зарурлыгы сюжетнең үзәгенә салынган[15].

Й. Гәрәйнең милли тәрбия концепциясендә туган тел – көндәлек аралашу, уку һәм хәтер мохите. «Саклыйк туган телне» мәкаләсендә ул мәктәп, уку-укыту системасы мисаллары аша телнең институциональ шартларга бәйле булуын күрсәтә: гаиләдә сөйләшү генә җитми, тел мәктәптә укытылырга, китапта, матбугатта һәм җәмәгать тормышында кулланылырга тиеш фикере үзәктә. Әлбәттә, автор күптеллелеккә каршы чыкмый. Аның үз тормышы башкорт, татар һәм рус телләре кисешендә үтә. Автор фикеренчә, туган телнең куллану дәрәҗәсен күтәрү зарур[16].

Әдәби хәтерне саклау өчен Й. Гәрәй Г. Тукай замандашларыннан истәлекләр җыя, Г. Ибраһимов геройларының прототипларын эзли, язучылар биографиясендәге даталарны архив документлары белән чагыштырып тикшерә. Мисал өчен, архивта сакланган материаллардан күренгәнчә, 1970 елның 28 маенда Афзал Шамов аңа Һади Такташның туу датасын Уфада сакланырга мөмкин метрика кенәгәләреннән ачыклау үтенече белән мөрәҗәгать итә. А. Шамов Й. Гәрәйнең «архив юлларын белүен» дә, Г. Ибраһимов турындагы истәлекләрне

туплауда башкарган эшен дә югары бәяли[17]. Бу хат Й. Гәрәйне язучы һәм публицист кына түгел, ә мәдәни хәтерне җыючы төбәк интеллектуалы буларак та ача. Мисал өчен, Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми?» әсәре герое прототибы турында килгән хатта информант үзенең Хәтимә килене белән сөйләшүен, гаилә әгъзалары һәм аларның язмышлары турында мәгълүмат туплавын хәбәр итә. Мондый материалларны турыдан-туры биографик факт дип кабул итеп булмый: аларда хәтер хатасы, ишетеп белү һәм даталар буталуы мөмкин. Әмма алар әдәби геройларның реаль прототипларын эзләү тарихын һәм төбәк җәмәгатьчелегенең әдәби мираска катнашуын күрсәтәләр[18].

Й. Гәрәй архивындагы истәлекләр, хатлар һәм автор тарафыннан тупланылган күптөрле материаллар милли тәрбиянең вакыт үлчәмен ача. Бишек җыры баланың телен ачтыра, китап аны киң мәдәни дөнья белән таныштыра, хат гаилә хәтерен саклый, истәлек һәм архив язучылар үткән буыннарның тәҗрибәсен киләчәккә тапшыра.

Й. Гәрәй текстларын бүгенге терминнар белән генә аңлату тарихи анахронизмга китерер иде. Аның публицистикасында «коммунистик тәрбия», «совет гражданины», «патриот», «коллектив» кебек чорга хас формулалар бар. 1960 елгы язмада, мисал өчен, «балалар китабы – дәүләт һәм комсомол җаваплылыгы» дип игълан ителә. 1979 елгы мәкаләдә совет балачак моделе капиталистик илләрдәге ярлылык һәм көч куллану күренешләренә каршы куела. Бу риторика чыганакларның идеологик катламын тәшкил итә.

Шул ук вакытта рәсми төшенчәләрнең конкрет эчтәлеге күбесенчә гаилә һәм авыл көнкүреше аша ачыла. Коллективизм – бәрәңге җыйганда ярдәм итү, уенчыкны урынына кую, ана хезмәтен күрү; гражданлык – җаваплылык; патриотизм – туган телне, авылны һәм әдәби хәтерне саклау; күпьяклы шәхес – техника белән эшләгәндә дә Г. Тукайны, җырны һәм юморны онытмау. Рәсми лексика, шулай итеп, язмаларда, көндәлек этика белән тулыландырылып мәгънә ала[19].

Милли үзенчәлек тә текстларда тышкы этнографик атрибутлар саны белән түгел, мөнәсәбәтләрне оештыру рәвеше белән билгеләнә. Бишек җырлары, уртак табын, чәк-чәк һәм токмач әзерләүгә салынган хезмәт, мәкаль белән фикерләү, хатны «карлыгач канаты» белән чагыштыру, исемнең мәгънәсенә игътибар – болар мәдәни тәҗрибәнең көндәлек формалары. Алар «үзгәрми торган милли характерны» түгел, татар һәм башкорт җәмгыятьләрендә кыйммәтләрнең совет модернизациясе шартларында ничек яңадан аңлатылуын күрсәтәләр.

Й. Гәрәйнең шәхси биографиясе бу катлаулы мөнәсәбәтнең ачык мисалы. Ул башкорт телендәге мәгариф һәм әдәбият үсешенә хезмәт итә, татар телен үзенең туган мәдәни нигезе итеп саный, рус һәм дөнья классикасына мөрәҗәгать итә. Әлеге позиция милли тел һәм хәтер аша башка мәдәниятләр белән тигез аралашу мөмкинлеген күрсәтә.

Йосыф Гәрәйнең 136нчы фондта сакланган документлары Идел-Урал төбәгендә XX гасыр милли мәгариф һәм мәдәни сәясәт тарихын комплексы өйрәнү өчен чыганак булып тора. Аның кыйммәте аерым кулъязмалар санында гына түгел, бер үк проблеманың төрле документ төрләрендә – рәсми беркетмәдә, суд белешмәсендә, шәхси хатларда, публицистик мәкаләләрдә, балалар хикәяләрендә һәм истәлекләрдә чагылуында.

1930 елларда формалашкан мәгариф эше һәм әдәби-оештыру тәҗрибәсе Й. Гәрәйгә балалар әдәбиятын мөстәкыйль мәдәни институт итеп карарга мөмкинлек бирә. Ул милли телдә оригиналь китаплар чыгаруны, яшь адресатын төгәл белүне, язучы һәм рәссамның уртак җаваплылыгын, фәнни дөреслек белән сәнгатьчә тәэсир бердәмлеген таләп итә. 1940 елгы репрессия бу эшчәнлекне өзә. 1956 елгы хат һәм 1957 елгы реабилитация белешмәсе әдәби метафораларның сәяси гаепләүгә әверелү механизмын, авторның үз текстын һәм исемен кире кайтару өчен көрәшен документлаштыра.

Реабилитациядән соңгы эшчәнлегендә ул элекке педагогик принципларның дәвамын һәм яңа тарихи мәгънәсен күрсәтә. Бала өлкәннәр карамагындагы пассив зат түгел, ул мәхәббәткә һәм хөрмәткә хаклы шәхес. Ана хезмәте, бишек җыры, туган тел, хатлар, әкиятләр милли тәрбиянең көндәлек механизмнары булып чыга. Шуңа күрә архив балалар әдәбиятын, бала һәм милли тәрбия тарихын идеологик лозунглар тарихы итеп кенә түгел, мәдәни нормаларның көндәлек тормышта үзләштерелү процессы итеп тә өйрәнергә мөмкинлек бирә.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. *Абдулхакова А. Р.* Из истории искусства татарской советской детской книги // Библиотековедение. – 2010. – № 3. – С. 56-60; *она же.* Татарская детская книга 1917-1991 гг.: эволюция и тенденции развития: дис. ... д-ра ист. наук. – Казань, 2010; *Мингазова Л. И.* Своеобразие и тенденции развития татарской детской литературы XX века. Автореф. дисс. ... д-ра филолог. наук / Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. – Казань, 2011. – 16 с.; *она же.* Татарская детская проза 1920-1960-х годов: тематика, проблемы, тенденции // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. – 2011. – № 4. – С. 246-253; *Маслинский К. А.* Переводы детских книг с языков народов СССР: библиографическая статистика (1922-1984) // Детские чтения. – 2024. – Т. 25. – № 1. – С. 49-73; *Мочалова Н. Ю.* Мифологема «счастливого детства» в советской детской литературе // KANT: Social Sciences & Humanities. – 2024. – № 2 (18). – С. 23-35.

2. *Мингазова Л. И.* История становления татарской детской литературы // Вестник Чувашского университета. – 2009. – № 4. – С. 314-317.

3. Мирасханә, 136 ф., 1 тасв., 70 сакл. бер.

4. Йосыф Гәрәйнең биографик, иҗади һәм хезмәт эшчәнлегенә бәйле материаллар // Мирасханә, 136 ф., 1 тасв., 54, 55, 57, 62 эш; Гарай (Гараев) Юсуф Ибрагимович // Татарская энциклопедия TATARICA. URL: tatarica.org (мөрәҗәгать итү датасы: 14.08.2026).

5. Шунда ук.

6. Мирасханә, 136 ф., 1 тасв., 64 эш, 5 кгз.; 56 эш, 176 кгз.

7. Шунда ук, 65 эш, 2 кгз.

8. Шунда ук, 17 эш, 55 кгз.

9. Шунда ук.

10. Шунда ук, 54 эш, 18 кгз.

11. Шунда ук.

12. Шунда ук.

13. Шунда ук, 17, 49 эш.

14. Шунда ук, 4 эш, 15, 20-21 кгз.

15. Шунда ук, 23-24, 27-29 кгз.

16. Шунда ук, 17 эш, 43-54 кгз.

17. Шунда ук, 47 эш, 143-149 кгз.

18. Шунда ук, 254-256 кгз.

19. Шунда ук, 54, 55, 57, 62 эш.

Әдәбият исемлеге

Абдулхакова А. Р. Из истории искусства татарской советской детской книги // Библиотековедение. – 2010. – № 3. – С. 56-60.

Абдулхакова А. Р. Татарская детская книга 1917-1991 гг.: эволюция и тенденции развития: дис. ... д-ра ист. наук. – Казань, 2010. – 445 с.

Мингазова Л. И. Своеобразие и тенденции развития татарской детской литературы. XX века: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 2011. – 16 с.

Мингазова Л. И. Татарская детская проза 1920-60-х годов: тематика, проблемы, тенденции // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. – 2011. – № 4. – С. 246-253.

Маслинский К. А. Переводы детских книг с языков народов СССР: библиографическая статистика (1922-1984) // Детские чтения. – 2024. – Т. 25. – № 1. – С. 49-73.

Мочалова Н. Ю. Мифологема «счастливого детства» в советской детской литературе // KANT: Social Sciences & Humanities. – 2024. – № 2 (18). – С. 23-35.

References

Abdulkhakova A. R. *Iz istorii iskusstva tatarskoj sovetskoj detskoj knigi* [From the history of the art of the Tatar Soviet children's book]. IN: *Bibliotekovedenie* [Russian Journal of Library Science], 2010, no. 3, pp. 56-60.

Abdulkhakova A. R. *Tatarskaya detskaya kniga 1917-1991 gg.: evolyutsiya i tendencii razvitiya: dis. ... d-ra ist. nauk* [Tatar children's book in 1917-1991: evolution and development trends: Dr. hist. sci. diss.]. Kazan, 2010, 445 p.

Mingazova L. I. *Svoeobrazie i tendencii razvitiya tatarskoj detskoj literatury XX veka: avtoref. dis. ... d-ra filol. nauk* [Specific features and development trends of twentieth century Tatar children's literature: abstract of Dr. philol. sci. diss.]. Kazan, 2011, 16 p.

Mingazova L. I. *Tatarskaya detskaya proza 1920-60-kh godov: tematika, problemy, tendencii* [Tatar children's prose of the 1920s-1960s: themes, problems and trends]. IN: *Vestnik Chelyabinskogo gosudarstvennogo pedagogicheskogo universiteta* [Bulletin of Chelyabinsk State Pedagogical University], 2011, no. 4, pp. 246-253.

Maslinsky K. A. *Perevody detskih knig s yazykov narodov SSSR: bibliograficheskaya statistika (1922-1984)* [Children's books translations from the languages of the peoples of the USSR: bibliographic statistics, 1922-1984]. IN: *Detskie chteniya* [Children's Readings], 2024, vol. 25, no. 1, pp. 49-73.

Mochalova N. Yu. *Mifologema "schastlivogo detstva" v sovetskoj detskoj literature* [The mythologeme of "happy childhood" in Soviet children's literature]. IN: KANT: Social Sciences & Humanities, 2024, no. 2 (18), pp. 23-35.

Сведения об авторе

Мингазова Ляйля Ихсановна, доктор филологических наук, профессор кафедры татарской литературы Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета, e-mail: Leila69@inbox.ru

About the author

Liailia I. Mingazova, Doctor of Philology, Professor at the Department of Tatar Literature, Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, e-mail: Leila69@inbox.ru

В редакцию статья поступила 18.08.2026, опубликована:

Миңнаҗева Л. И. Йосыф Гәрәй архивында балалар әдәбияты: милли тәрбия һәм традицион кыйммәтләр // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2026. – № 4. – С. 192-199.

Submitted on 18.08.2026, published:

Mingazova L. I. *Iosyf Garai arkhivynda balalar edebiyaty: milli terbiya hem traditsion kyimmetler* [Children's literature in Yusuf Garey's archive: national upbringing and traditional values]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov* [Echo of centuries], 2026, no. 4, pp. 192-199.